КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 ноябрь г.Казань № 872

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2017 елгы премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты, аларның иминлеген тәэмин итү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән, шулай ук сыйфат белән идарә итүнең югары нәтиҗәле ысулларын керткән өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2017 елгы премияләрен «Эшлекле камиллек» номинациясендә түбәндәгеләргә бирергә:

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык куллануы товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «А.М.Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлар җәмгыятенә (Зеленодольск шәһәре); «Казан компрессорлы машиналар төзү заводы» акционерлар җәмгыятенә (Казан шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – җаваплылыгы чикләнгән «Татнефть-АЗС Центр» җәмгыятенә (Әлмәт шәһәре); «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре);

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык куллануы товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – җаваплылыгы чикләнгән «ТаграС-ЭнергоСервис» җәмгыятенә (Әлмәт шәһәре), җаваплылыгы чикләнгән «Агропласт» җәмгыятенә (Яр Чаллы шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «Ижминводы» шифаханәсе дәвалау-профилактикалау шәхси һөнәр ияләре берлекләре учреждениесенә (Менделеевск районы), «18 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре);

«Җитештерү системалары» номинациясендә:

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең Бөгелмә механика заводына (Бөгелмә шәһәре), «КАМАЗ» гавами акционерлар җәмгыятенең Двигательләр заводына (Яр Чаллы шәһәре).

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2017 елгы премияләренә дәгъва итү конкурсы лауреатларын һәм дипломантларын бүләкләү тантанасын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\872.docx